ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 141 от «14» 04 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
2025 елның 1 февралендә кабул ителгән
44 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак Кодексының 156, 158 статьялары, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә эшен оештыру принциплары турындагы» 131-ФЗ номерлы Федераль Закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 1 февралендә кабул ителгән “2025 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү тарифларын раслау турында” 44 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар белән расланган социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен торак хезмәтләре тарифларын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Нократ» («Вятка») район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.М.Гарипов

0000012674

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының
14 04 2024 ел,
№141 карарына
кушымта

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен торак хезмәтләре тарифлары

| Хезмәт исеме | Түләү алынучы үлчәү берәмлеге | Бер төр хезмәткә алынучы түләү тарифы, 2025 елның 1 гыйнварыннан | Бер төр хезмәткә алынучы түләү тарифы 2025 елның 1 июленнән |
|---|---|---|---|
| Торак фонды белән идарә итү | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 3,07 | 3,07 |
| Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 2,44 | 2,44 |
| Йорт яны территориясен җыештыру | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 2,22 | 2,22 |
| Гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 3,03 | 3,03 |
| Дератизация (дезинфекция) | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 0,15 | 0,15 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау: | | | |
| - йорт эчендәге санитар-техник челтәрләр | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 1,2 | 1,2 |
| - йорт эчендәге газ челтәрләре | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 0,26 | 0,26 |
| - йорт эчендәге электр белән тәэмин итү челтәрләре | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 1,03 | 1,03 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| - йорт эчендәге үзәкләштерелгән җылыту челтәрләре | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 1,65 | 1,65 |
| Вентиляция каналларына хезмәт күрсәтү | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 0,60 | 0,60 |
| Төтен чыгару юлларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 0,60 | 0,60 |
| Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 13,00 | 13,00 |
| Телевидениене күмәк кабул итү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау (булган очракта) | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 0,43 | 0,43 |
| Янгынга каршы автоматика системалары (хезмәтләр булганда) | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 1,18 | 1,18 |
| Контейнер мәйданчыкларын карап тоту | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 1,92 | 1,92 |
| Домофонга хезмәт күрсәтү | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 0,45 | 0,45 |
| Йорт эчендәге газ җайланмасына техник диагностика ясау (түләү диагностика ясау срогы башланганчы 12 ай эчендә исәпләнә) | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 0,70* | 0,70* |

* газүткәргечне файдалануга тапшыруга 30 ел узган КФЙ өчен